
ӘКИЯТ
ТӨРЛӘРЕ

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр батырлар.
Бар бит анда ак аюлар,
Көчле Камыр Батырлар
Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр шаяннар:
Йөгерештә җилаяклар,
Чакмый торган Чаяннар.
Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр хәйләле:
Чөнки анда зирәк Былтыр,
Тагын елак Шүрәле...
Серле,кызык әкиятләрне
Тыңларга бик яратам.
Әкият сөйләгәннәрен
Көн саен көтеп алам.

(Э. Шәрифуллина)

Әкият – ул халык авыз иҗатының төп жанрларыннан берсе булып, уйдырмага таянган, тылсымлы, маҗаралы яисә көнкүреш характерындагы эпик сәнгать әсәре.

Әкият гарәпчә хикәят – сөйләп бирү дигәнне аңлата.

Керәшен татарлары әкиятне мәсәл дип йөртәләр.

Себер татарлары әкияткә йомык диләр.



Әкиятләр өч төргә бүлеп карала:

1) хайваннар турындагы әкиятләр;
2) тылсымлы әкиятләр;
3) тормыш-көнкүреш әкиятләре.



DreamWorlds.ru

# Хайваннар турындагы әкиятләр

*Татар халык әкиятләре арасында хайваннар турындагылары бик аз. Бу әсәрләрнең күләмнәре дә зур түгел. Аларның төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре һәм җәнлекләре, кошлар һ.б. Безгә таныш булганнары: “Салам-Торхан”, “Аю, Бабай, Төлке”, “Кәтән Иваныч”, “Торна белән Төлке”, “Кәҗә белән Сарык”.*

Rylik.ru



Аю – көчле, ләкин аңгыра булып сурәтләнә.


Төлке – хәйләкәр, алдакчы булып сурәтлән
pikabu.ru

**Куян куркак хайван буларак сурәтләнә.**



# Тылсымлы әкиятләр

*Бу төрдәге әкиятләр күбрәк. Тылсымлы әкиятләрнең күбесенә түбәндәге сюжет хас: булачак герой, үсеп җиткәч, ил гизәргә чыгып китә, төрле маҗараларга очрый, патша кызын аждаһа яки диюләрдән коткара, яисә патша йөкләгән авыр бурычларны үти һәм нәтиҗәдә, әлеге патша кызына өйләнеп, үзе патша булып кала.*




**Уңай образ итеп**



**Аждаhа - тылсымлы әкиятләрдә иң күп очрый торган дошман персонаж**



# Убырлы карчык

Урманда кечкенә өйдә яши.

Ул усал һәм рәхимсез, кешеләрне йота, ләкин мүҗбүр иткәндә, йоткан кешеләрне сау-сәламәт рәвештә кире дә чыгара.

Кайбер әкиятләрдә Ул кешеләргә ярдәм дә итә. (“Үги кыз”)

Бу затлардан тыш, тылсымлы әкиятләрдә, геройның дошманнары буларак җен, пәриләр очрый.

Тылсымлы ат, күгәрчен, алтын балык, ак бүре, сәмруг кош һ.б. уңай образлар итеп сурәтләнәләр, алар әкият героена ярдәм итәләр.

## Тормыш-көнкүреш әкиятләре

**Бу төрдәге әкиятләр башка төрдәге әкиятләрдән реаль чынбарлыкка гаять якын торулары белән аерылалар. Бу әсәрләр сыйнфый-социаль яисә мораль-этик конфликтка корылган, һәм аларның күбесе элекке авыл тормышын чагылдыра.**



**“Өч кыз” әкияте – иң яраткан әкиятләремнең берсе. Ул безне әти-әниләргә ярдәм итәргә, үскәч аларны онытмаска, шәфкатьле, ярдәмчел булырга өйрәтә.**

Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият явызлыкны гаепли, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, мәрхәмәтле булырга өйрәтә.